СОВЕТ
НОВОКЫРЛАЙСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Центральная, д. 3, с.Новый Кырлай,
Арский муниципальный район, 422035

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЯҢА КЫРЛАЙ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ
Үзәк урам, 3 йорт, Яңа Кырлай авылы,
Арча муниципаль районы, 422035

Тел. (84366)56-7-32, факс (84366)56-7-34. E-mail: Nkrl.Ars@tatar.ru

**Яңа Кырлай авыл җирлеге советы**
**карары**

**“29” ноябрь 2023 ел** **№ 84**

Яңа Кырлай авыл җирлеге Советының 2022 елның 22 августында кабул ителгән “Җир салымы турында” 56 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында (2022 елның 29 декабрендә кабул ителгән 67 номерлы карары редакциясендә)

2023 елның 31 июлендәге 389-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Яңа Кырлай авыл җирлеге Уставына таянып, Яңа Кырлай авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Яңа Кырлай авыл җирлеге Советының 2022 елның 22 августындагы 56 номерлы “Җир салымы турында”гы карарына (2022 елның 29 декабрендә кабул ителгән 67 номерлы карары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

2 пунктның 2.4 нче пункт астындагы “һәм объектлар белән” сүзләрен “һәм (яки) объектлар белән”, “объектка туры килә торган җир участогына хокуклы өлеш” сүзләрен “күчемсез милек объектына туры килә торган җир участогы өлешләре” һәм “һәм объектларга” сүзләрен “һәм (яки) объектларга” сүзләре белән алыштырырга;

2. Әлеге карарның 1 пунктының гамәлдә булуы 2024 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

3. Әлеге карар Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http:pravo.tatarstan.ru) һәм Арча муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында рәсми рәвештә бастырылганнан соң бер ай узгач кына үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Яңа Кырлай авыл җирлеге башлыгы Г.Г. Сәфәров